ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**17.03.2025**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 683**

2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен 2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең максималь күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган *керемнең* максималь күләме:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 77 815,54 сум;
1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 77 815,54 сум;
1.1.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 77 815,54 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле *мөлкәт хакының* максималь күләме түбәндәгеләрне тәшкил итә:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 606 176,00 сум;
1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 3 212 352,00 сум;
1.2.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 4 818 528,00 сум;
1.2.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 6 424 704,00 сум;
1.2.5. биш кешедән торган гаилә өчен – 8 030 880,00 сум;
1.2.6. алты кешедән торган гаилә өчен – 9 637 056,00 сум;
1.2.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 11 243 232,00 сум.

2. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда, «Зеленодольск муниципаль районы торак сәясәте департаменты» МКУ муниципаль торак фонды бүлегенә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында билгеләнгән күрсәткечләрне кулланырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2025 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматы рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин